Татарстан Республикасы
Азнакай муниципаль районы
Илбәк авыл җирлеге
Башкарма комитеты

Ә.Вәлиев урамы, 53нче йорт, Илбәк авылы,
Азнакай районы, 423321

Республика Татарстан
Исполнительный комитет
Ильбяковского сельского поселения
Азнакаевского муниципального
района

ул. А.Валеева, д. 53, село Ильбяково,
Азнакаевский район, 423321

Тел. (факс) 8(85592) 38-5-38; e-mail: Ilb.Azn@tatar.ru;
http://aznakayevo.tatarstan.ru/

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

«16» март 2021 ел № 7

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Илбәк авыл җирлеге» территориясендә урнашкан су объектларында су коенуны тыю турында

Россия Федерациясе Су кодексының 6 статьясындагы 4 өлеше, Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясенең 2020 елның 12 маендагы № 13-20р күрсәтмәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы « Илбәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә халыкның күпләп ял итүе һәм суда коткару чаралары өчен җиһазландырылган урыннар булмау сәбәпле, су объектларының һәм елгаларының санитария-гигиена нормаларына туры килмәве, елгаларда һәм сулыкларда бәхетсезлек очракларының иминлеген тәэмин итү, кисәтү һәм санын киметү максатыннан Илбәк авыл җирлеге Башкарма комитеты карар итә:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Илбәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан су объектларында су коенуны тыярга.

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы территориясендә урнашкан « Илбәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең барлык милек рәвешләрендәге предприятие, оешма, учреждениеләр җитәкчеләренә су объектларында су коенуны тыю турындагы әлеге карар белән танышуны тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.

3. Илбәк авыл җирлеге Башкарма комитетына су объектлары янында су коенуны тыю турындагы мәгълүмат белән кисәтү аншлаглары урнаштырырга.

4. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында" түбәндәге веб -адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының мәгълүмат сайтында "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatarstan.ru.

Башлык Л.Р.Әсәдуллина